# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# РУС ӘҖӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2021 елның 19 ноябре № 48

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу булган вәкаләтләрен Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендагы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу булган вәкаләтләрен тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына Яшел Үзән муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча, аның предметы булып, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу булган вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә тәкъдим итәргә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен тормышка ашыруны Яшел Үзән муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлеге бюджетыннан ел саен Яшел Үзән муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкаралар.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү комиссиясенә йөкләргә.

**Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Г.Ф.Семахина**